ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СОБОЛЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
СОБОЛЕВСКИЙ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР

24.03.2021 с. Соболевское № 10

Соболевский авыл җирлегендә 2021нче елның язгы чорында җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү турында.

"Автомобиль юллары һәм Россия Федерациясендә юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында" 2007нче елның 8нче ноябрендәге 257-ФЗ номерлы Федераль закон, "Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында" 2009нчы елның 3нче августындагы 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төбәк яисә муниципальара, җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләүне яисә вакытлыча туктатып торуны гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2013нче елның 31нче маендагы 372нче номерлы карары, Соболевский авыл җирлеге Уставы нигезендә, уңайсыз табигый-климат шартлары барлыкка килгән чорда җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының конструктив элементларының чынбарлыктагы сәләтен киметүне булдырмау максатларында,

КАРАР БИРӘМ:

1. 2021нче елның 1нче апреленнән 30нчы апреленә кадәр Соболевский авыл җирлегенең җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында транспорт чарасы күчәренә 6 тоннадан артык массасы туры килгән йөк белән яисә йөксез транспорт чаралары хәрәкәтенә вакытлыча чикләүне кертергә (алга таба-язгы чорда хәрәкәтне вакытлыча чикләү).

2. Хәрәкәтне вакытлыча чикләү 3.12 "Транспорт чарасына туры килә торган массаны чикләү" юл билгеләрен урнаштыру юлы белән Россия Федерациясе Юл хәрәкәте кагыйдәләре белән каралган өстәмә мәгълүмат (табличкалар) 8.20.1 һәм 8.20.2 "Транспорт чаралары тибы" тамгалары белән гамәлгә ашырыла.

3. Россия Эчке эшләр министрлыгының «Югары Ослан» муниципальара бүлеге ЮХИДИ бүлегенә Югары Ослан муниципаль районы Соболевский авыл җирлегенең автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү режимын үтәүне контрольдә тотуны оештырырга тәкъдим итәргә.

4. 2021нче елның 1нче апреленә кадәр авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында һәм Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында вакытлыча чикләүләр кертү турында мәгълүмат урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен үзем контрольдә тотам.

Югары Ослан муниципаль районы
Соболевский авыл җирлеге башлыгы О. Н. Майорова